**Фигыль.** Фигыль турында үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү.Татар телендәфигыльнең нигезе (башлангыч формасы) турында гомуми мәгълүмат.

Сыйфат фигыль, аның мәгънәсе һәм заман формалары. Сыйфат фигыльләрнең сөйләмдә кулланылышы.

Хәл фигыль, аның мәгънәләре, формалары, сөйләмдә кулланылышы.

Фигыльләрнең ясалышы.

Фигыльләргә морфологик анализ ясау.

**Аваз ияртемнәре** турында гомуми мәгълүмат.Аларның ясалуы,морфологик-синтаксик үзенчәлекләре. Аваз ияртемнәреннән ясалган исемнәр һәм фигыльләр.

Кабатлау.

**Хәбәрлек сүзләр.** Татар телендә хәбәрлек сүзләр турында төшенчә.Хәбәрлексүзләрнең формалары һәм җөмләдә кулланылышы.

**Теркәгечләр** турында гомуми мәгълүмат.Аларны төркемләү.

Теркәгеч сүзләр. Татар һәм рус телләрендә теркәгечләрнең уртак яклары, аларның җөмләдә кулланылышы.

**Синтаксис.** Гади җөмлә турында үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү.Сәбәп хәле,максат хәле, шарт хәле, кире хәл, аларның аерымлануы.

**Ел буена үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау.**

**Бәйләнешле сөйләм үстерү.**

**VII сыйныф укучыларының белем, осталык һәм күнекмәләренә таләпләр:**

- өйрәнгән темаларга караган тел берәмлекләрен телдән һәм язма сөйләмдә тиешенчә куллана белү;
- өйрәнгән сүз төркемнәренең сөйләмдә кулланылу үзенчәлекләрен аңлау, аларны табигать күренешләрен, аерым предмет һәм кешеләрне телдән һәм язмача тасвирлаганда файдалана белү;
- укытучы биргән тексттагы җөмләләрдән кирәкле морфологик һәм синтаксик берәмлекләрне таба белү;
- тел дәресләрендә өйрәнгән темаларга караган берәмлекләрне татарчадан русчага һәм русчадан татарчага тәрҗемә итү күнегүләрен үтәү;
- изложение һәм сочинение язганда, орфографик һәм пунктуацион нормаларны саклап эш итү.

**VIII сыйныф**

**V – VII сыйныфларда үткәннәрне кабатлау.**

**Морфология.**

**Сыйфат** белән **рәвеш** турында үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү.Аларарасындагы охшашлыкларны һәм аермаларны күзәтү.

**Фигыль** турында үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү.Исем фигыль,аныңмәгънәсе, формасы, сөйләмдә кулланылышы.

Инфинитив фигыль. Аның мәгънәсе, формалары, сөйләмдә кулланылышы һәм дөрес язылышы.

Ярдәмче фигыльләр, аларның сөйләмдә кулланылышы.

**Кисәкчәләр** турында гомуми мәгълүмат.Аларны мәгънәләре буенча төркемләү. Татар телендә кисәкчәләрнең дөрес язылышы.

**Ымлыклар** турында гомуми мәгълүмат.Аларның ясалу үзенчәлекләре һәмсөйләмдә кулланылышы. Ымлыкларны төркемләү.

**Синтаксис.**

Хәлләр турында үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү.

Сүзләр арасында тезүле бәйләнеш. Җөмләнең тиңдәш кисәкләре, алар янында гомумиләштерүче сүзләр һәм тыныш билгеләре.

Сүзләр арасында ияртүле бәйләнеш. Сүзтезмә, андагы ияртүче һәм ияртүче кисәкләр. Татар телендә сүзтезмәләрнең төрләре.

Җөмлә кисәкләренең урнашу тәртибе, аның рус телендәге сүзләрнең урнашу тәртибеннән аермалы яклары.

Гади җөмлә турында үтелгәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү.

Әйтү максаты буенча җөмлә төрләре. Хикәя җөмлә, сорау җөмлә, боеру җөмлә һәм тойгылы җөмләләр (үтелгәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү) һәм алар янында куела торган тыныш билгеләре.

Эндәш сүз һәм кереш сүз турында гомуми төшенчә. Аларның үзенчәлекләре һәм җөмләдәге урыны. Эндәш һәм кереш сүзләр янында тыныш билгеләре.

Раслау һәм инкяр җөмләләр һәм аларның кулланылышы.

Гади җөмләләргә синтаксик анализ ясау.

**Гади җөмлә синтаксисын һәм анда кулланыла торган тыныш билгеләрен гомумиләштереп кабатлау.**

**Бәйләнешле сөйләм үстерү.**

**VIII сыйныф укучыларының белем, осталык һәм күнекмәләренә таләпләр:**

- телдән һәм язма сөйләмдә өйрәнгән сүз төркемнәренең формаларын урынлы куллану;
- гади җөмләләрнең төрле формаларын кулланып, дәрестә өйрәнелә торган тема турында сөйләү, аларга караган мисаллар әйтү (язу);
- гади җөмләләргә синтаксик анализ ясаганда, телдән һәм язмача аңлату, җөмлә кисәкләрен шартлы билгеләр белән күрсәтү.

**IX сыйныф**

**Синтаксис буенча VIII сыйныфта өйрәнгәннәрне кабатлау.**

**Кушма җөмлә синтаксисы һәм сөйләм культурасы.**

Кушма җөмлә турында гомуми төшенчә. Кушма җөмлә составындагы җөмләләрнең бәйләнеш төрләре.

Кушма җөмлә төрләре. Тезмә кушма җөмләләр турында үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү (теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр, алар янында тыныш билгеләре).

Иярченле кушма җөмләләр турында гомуми мәгълүмат. Аналитик иярченле кушма җөмләләр. Синтетик иярченле кушма җөмләләр. Аналитик һәм синтетик иярченле кушма җөмләләрдә бәйләүче чаралар һәм тыныш билгеләре.

Татар һәм рус телләрендә тезмә һәм иярченле кушма җөмләләр. Аларның охшаш һәм үзенчәлекле билгеләре.

Иярчен җөмләләрнең мәгънә ягыннан төрләре. Җөмлә кисәкләре белән иярчен җөмлә төрләре арасындагы мәгънә бәйләнеше.

Иярчен ия җөмләләр. Иярчен хәбәр җөмләләр.

Иярчен аергыч җөмләләр. Иярчен тәмамлык җөмләләр.

Иярчен хәл җөмләләр: иярчен вакыт, иярчен урын, иярчен рәвеш, иярчен күләм, иярчен сәбәп, иярчен максат, иярчен шарт һәм иярчен кире җөмләләр.

**Текст һәм пунктуация.**

Текст турында гомуми төшенчә. Туры һәм кыек сөйләм, алар янында тыныш билгеләре.

**Синтаксис һәм пунктуацияне гомумиләштереп кабатлау. Җөмләләргә синтаксик анализ ясау.**

**Сөйләм культурасы.**

Әдәби сөйләмнең төп билгеләре: дөрес, ачык, эзлекле, сәнгатьле, аһәңле, җыйнак, матур яңгырашлы сөйләм. Татар әдәби теленең байлыгы һәм тәэсирле булуы. Сөйләмдә калькаларны урынлы куллану.

**V– IX сыйныфларда үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау.**

**Бәйләнешле сөйләм үстерү.**

**Этнокультура өлкәсенә караган компетенцияне булдыруны һәм үстерүне тәэмин итүнең эчтәлеге**

Бу бүлеккә караган материалларны өйрәнү аралашу һәм лингвистик компетенцияләрне гамәлгә ашырганда башкарыла һәм аны укытучы үзе оештыра.

Тел һәм мәдәният. Телдә халык тарихы һәм мәдәниятенең чагылышы.

Татар сөйләм әдәбенә караган сүзләр, аларны урынлы куллану.

Төрле халыкларның тормыш-көнкүрешен чагылдырган сүзләрне файдалану.

Сүз сәнгатенең образлы табигатен аңлый белүгә ирешү.

**Туган телне укыту предметының уку эшчәнлеге төрләре күрсәтелгән тематик планы**

| Программаның төп темалары | Сәгатьләр саны | Уку эшчәнлегенең төп төрләре |
|---|---|---|
| **5 класс- 70 сәгать** | | |
| Фонетика, орфоэпия, графика һәм орфография.<br>Сузык авазлар. Аңкау һәм ирен гармониясе.<br>Тартыкларның сөйләмдәге үзгәрешләре.<br>Аваз һәм хәреф төшенчәләре. Алфавит.<br>*Я, ю, е* хәрефләренең дөрес язылышы.<br>*ъ* һәм *ь* хәрефләренең дөрес язылышы.<br>Сүзләргә фонетик анализ ясау. | 28 | Фонетиканың төп төшенчәләрен белү.Сузыкһәмтартык авазларны тану. Телдән һәм транскрипция элементлары буенча аерым сүзләрне, сүзнең әйтелү һәм язылу үзенчәлекләрен, сөйләмдәге авазларны билгеләү. Сүзләргә фонетик анализ ясау. Авазларны классификацияләү һәм төркемнәргә аеру.<br>Орфографик сүзлекне файдалану. Сүзнең аваз-хәреф составын чагыштыру һәм анализлау. Сүзлекләрдән һәм энциклопедияләрдән кирәкле мәгълүматны табу өчен, алфавитны белү. |
| Лексика һәм лексикография.<br>Лексика турында гомуми мәгълүмат.<br>Сүзнең лексик мәгънәсе.<br>Сүзләрнеңтурыһәм күчерелмә мәгънәләре.<br>Фразеологик әйтелмәләр, аларның сөйләмдә кулланылышы.<br>Төрле типтагы сүзлекләрнең төзелү принциплары, алардан дөрес файдалану. | 11 | Фикерне һәм хисне белдерүдә сүзнең ролен аңлау.<br>Сүзнең лексик мәгънәсенә төшенү.<br>Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләрне, туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләрне аеру; омоним, синоним, антонимнарны тану.<br>Синонимнарның мәгънәви һәм стилистик аермалыкларын аңлау.<br>Туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләрне чагыштыру.<br>Сүзләрне килеп чыгышы, кулланылу өлкәсе һәм ешлыгы ягыннан аеру.<br>Сөйләмдә синонинар, антонимнар, бер тематик төркемдәге сүзләрне, омонимнарны һәм күп мәгънәле сүзләрне куллану. Аңлатмалы, синонимнар, антонимнар, фразеологик сүзлекләрдән кирәкле мәгълүматны табу.<br>Сөйләмдәге фразеологик әйтелмәләрне тану һәм урынлы куллану. |
| Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы.<br>Тел белеменең бүлеге буларак сүз төзелеше һәм сүз ясалышы. Тамырдаш | 15 | Сүз тамырын һәм кушымчаларны мәгънәле кисәкләр буларак, сүз ясаганда, |

| | | |
|---|---|---|
| сүзләр. Сүзнең тамыры һәм кушымчалары. Төрле сүз төркемнәрен ясый торган кушымчалар. Бәйләгечләр (килеш кушымчалары), модальлек (күплек сан, иркәләү-кечерәйтү) кушымчалары. Сүз ясалу ысуллары: ясагыч кушымчалар ярдәмендә сүз ясалу, сүзләрне кушу яки теркәү ярдәмендә сүз ясау, сүзләрне кыскарту юлы белән яңа сүз ясалу.<br>Сүз төзелешен һәм ясалышын тикшерү, төрле сүзлекләр куллану. | | ясагыч кушымчаның әһәмиятен аңлау. Сүзләрне мәгънәле кисәкләргә бүлү.<br>Өйрәнелгән сүз төркемнәреннән исемнәрнең, сыйфатларның һәм фигыльләрнең сүз ясалыш ысулларын аеру.<br>Язуда сүз төзелеше һәм сүз ясалышы буенча булган белем һәм күнекмәләрне куллану. |
| Бәйләнешле сөйләм үстерү. | 16 | Сөйләмне стилистик һәм орфоэпик яктан дөрес итеп оештыру. Укучыларның актив һәм пассив сүзлек байлыгын үстерү. Диалогик һәм монологик сөйләм формаларына ия булу. Үз фикереңне белдерү, аны нигезләү. Кешеләр белән аралашканда, татар сөйләм әдәбе үзенчәлекләрен саклау. |
| **6 класс-70 сәгать** | | |
| Морфология.<br>Сүз төркемнәре турында гомуми мәгълүмат.<br>Исем. Исем турында үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү.<br>Тартым турында мәгълүмат бирү. Исемнәрнең тартым белән төрләнеше.<br>Алынма сүзләрдәге килеш һәм тартым кушымчалары.<br>Исемнәрнең төрле ысуллар белән ясалышы.<br>Исемнәргә морфологик анализ ясау.<br>Сыйфат. Сыйфат турында үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү.<br>Асыл һәм нисби сыйфатлар. Сыйфатларның төрле ысуллар белән ясалышы.<br>Сыйфатларга морфологик анализ ясау.<br>Рәвеш турында гомуми мәгълүмат. Саф, охшату-чагыштыру һәм күләм-чама рәвешләре, аларның җөмләдә кулланылышы.<br>Рәвешләргә морфологик анализ ясау.<br>Сан. Сан турында үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү.<br>Сан төркемчәләре: чама саны, бүлем саны, җыю саны.<br>Саннарның ясалышы, аларның дөрес язылышы.<br>Саннарга морфологик анализ ясау.<br>Алмашлык. Амашлыклар турында үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү. | 38 | Сүз төркемнәренә лексик-грамматик мәгънәләре, морфологик һәм синтаксик билгеләре буенча характеристика бирү. Аларның мәгънә төркемчәләрен аеру, морфологик формаларын телдән һәм язма сөйләмдә урынлы куллану һәм аларга мисаллар китерү.<br>Сүз төркемнәренең ясалыш ысулларын билгеләү, аларга морфологик анализ ясау, матур әдәбият әсәрләрендә кулланылу үзенчәлекләрен ачыклау. |

| | | |
|---|---|---|
| Билгеләү, билгесезлек һәм юклык алмашлыклары. Аларның җөмләдә кулланылышы.<br>Алмашлыкларны морфологик яктан тикшерү.<br>Фигыль. Фигыль турында үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү.<br>Шарт фигыль турында төшенчә, аларның зат-сан белән төрләнеше, сөйләмдә кулланылышы.<br>Фигыльләргә морфологик анализ ясау.<br>Бәйлекләр турында гомуми мәгълүмат.<br>Аларның сөйләмдә кулланылу үзенчәлекләре.<br>Бәйлекләрне төркемләү.<br>Бәйлек сүзләр, аларның җөмләдә кулланылышы. | | |
| Синтаксис.<br>Гади җөмлә турында үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү. Раслау һәм инкарь җөмләләр.<br>Рәвеш хәле һәм күләм хәле, аларның аерымлануы.<br>Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр, алар янындагы тыныш билгеләре. | 17 | Гади җөмлә төрләре турында үткәннәрне искә төшерү, ныгыту һәм тирәнәйтү. Иярчен кисәкләрдән хәлләрне өйрәнүне дәвам итү, аларны телдән һәм язма сөйләмдә тиешенчә куллану. Тезмә кушма җөмлә төрләрен өйрәнүгә бәйле рәвештә тыныш билгеләрен тиешенчә кую күнекмәләрен булдыру. |
| Бәйләнешле сөйләм үстерү | 15 | Диалогик һәм монологик сөйләм формаларына ия булу. Үз фикереңне белдерү һәм аны дәлилләү. Татар телен начаррак белүче кешеләр белән аралашканда, татар сөйләм әдәбе үзенчәлекләрен саклау.<br>Тәкъдим ителгән текстның планын төзү. Әзер план буенча текст төзү. |
| **7 класс- 70 сәгать** | | |
| Морфология.<br>Исем. Исем турында үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү. Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше.<br>Исемнәрнең җөмләдә кулланылышы.<br>Сыйфат. Сыйфат турында үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү. Сыйфатның исемләшүе.<br>Сыйфатларның җөмләдә кулланылышы.<br>Рәвеш. Рәвеш турында үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү. Урын, вакыт һәм сәбәп-максат рәвешләре.<br>Рәвешләрнең җөмләдә кулланылышы.<br>Фигыль. Фигыль турында үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү. Татар телендә | 35 | Сүз төркемнәренә лексик-грамматик мәгънәләре, морфологик һәм синтаксик билгеләре буенча характеристика бирү. Аларың мәгънә төркемчәләрен аеру, морфологик формаларын телдән һәм язма сөйләмдә урынлы куллану һәм аларга мисаллар китерү.<br>Сүз төркемнәренең ясалыш ысулларын билгеләү, аларга морфологик анализ ясау, матур әдәбият әсәрләрендә кулланылу үзенчәлекләрен ачыклау. |

| | | |
|---|---|---|
| фигыльнең нигезе (башлангыч формасы) турында гомуми мәгълүмат. Сыйфат фигыль, аның мәгънәсе һәм заман формалары. Сыйфат фигыльләрнең сөйләмдә кулланылышы. Хәлфигыль,аныңмәгънәләре, формалары, сөйләмдә кулланылышы. Фигыльләрнең ясалышы. Фигыльләргә морфологик анализ ясау. Аваз ияртемнәре турында гомуми мәгълүмат. Аларның ясалуы, морфологик-синтаксик үзенчәлекләре. Аваз иялтемнәреннән ясалган исемнәр һәм фигыльләр. Хәбәрлексүзләр.Татартелендә хәбәрлек сүзләр турында төшенчә. Хәбәрлек сүзләрнең формалары һәм җөмләдә кулланылышы. Теркәгечләр турында гомуми мәгълүмат. Теркәгечләрне төркемләү. Теркәгеч сүзләр. Татар һәм рус телләрендә теркәгечләрнең уртак яклары, җөмләдә кулланылышы. | | |
| Синтаксис.<br>Гади җөмлә турында үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү. Сәбәп хәле, максат хәле, шарт хәле, кире хәл, аларның аерымлануы. | 15 | Гади җөмлә төрләре турында үткәннәрне искә төшерү, ныгыту һәм тирәнәйтү. Иярчен кисәкләрдән хәлләрне өйрәнүне дәвам итү, аларны телдән һәм язма сөйләмдә тиешенчә куллану.<br>Аерымланган хәлләрне өйрәнүгә бәйле рәвештә тыныш билгеләрен тиешенчә кую күнекмәләрен булдыру. |
| Бәйләнешле сөйләм үстерү. | 20 | Диалогик һәм монологик сөйләм формаларына ия булу. Үз фикереңне белдерү һәм аны дәлилләү. Татар телен йомшак белүче кешеләр белән аралашканда, татар сөйләм әдәбе үзенчәлекләрен саклау.<br>Текст өстендә эшләү: аңа исем бирү, планын төзү. Тәкъдим ителгән план буенча текст төзү. |
| **8 класс- 70 сәгать** | | |
| Морфология.<br>Сыйфат белән рәвеш турында үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү. Алар арасындагы охшашлыкларны һәм аермаларны күзәтү.<br>Фигыль. Фигыль турында үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү. Исем фигыль, аның мәгънәсе, формасы, сөйләмдә кулланылышы. | 20 | Сүз төркемнәренә лексик-грамматик мәгънәләре, морфологик һәм синтаксик билгеләре буенча характеристика бирү. Аларың мәгънә төркемчәләрен аеру, морфологик формаларын телдән һәм язма сөйләмдә урынлы куллану һәм аларга мисаллар |

| | | |
|---|---|---|
| Инфинитив фигыль. Аның мәгънәсе, формалары, сөйләмдә кулланылышы һәм дөрес язылышы.<br>Ярдәмче фигыльләр, аларның сөйләмдә кулланылышы.<br>Кисәкчәләр турында гомуми мәгълүмат. Аларны мәгънәләре буенча төркемләү. Татар телендә кисәкчәләрнең дөрес язылышы.<br>Ымлыклар турында гомуми мәгълүмат.<br>Аларның ясалу үзенчәлекләре һәм сөйләмдә кулланылышы. Ымлыкларны төркемләү. | | китерү.<br>Сүзтөркемнәренең ясалыш ысулларын билгеләү, аларга морфологик анализ ясау, матур әдәбият әсәрләрендә кулланылу үзенчәлекләрен ачыклау |
| Синтаксис.<br>Хәлләр турында үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү. Сүзләр арасында тезүле бәйләнеш. Җөмләнең тиңдәш кисәкләре, алар янында гомумиләштерүче сүзләр һәм тыныш билгеләре.<br>Сүзләр арасында ияртүле бәйләнеш.<br>Сүзтезмә, андагы ияртүче һәм иярүче кисәкләр. Татар телендә сүзтезмәләрнең төрләре.<br>Җөмлә кисәкләренең урнашу тәртибе, аның рус телендәге сүзләрнең урнашу тәртибеннән аермалы яклары.<br>Гади җөмлә турында үтелгәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү.<br>Әйтү максаты буенча җөмлә төрләре. Хикәя җөмлә, сорау җөмлә, боеру җөмлә һәм тойгылы җөмләләр (үтелгәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү) һәм алар янында куела торган тыныш билгеләре.<br>Эндәш сүз һәм кереш сүз турында гомуми төшенчә. Аларның үзенчәлекләре һәм җөмләдәге урыны. Эндәш һәм кереш сүзләр янында тыныш билгеләре.<br>Раслау һәм инкяр җөмләләр һәм аларның кулланылышы. | 30 | Синтаксисның төп берәмлекләрен аера белү (сүзтезмә, җөмлә); сүзтезмә һәм җөмләләрне төзелеше һәм мәгънәле кисәкләренең бәйләнеше ягыннан төрләрен билгеләү һәм тикшерү; җөмләнең грамматик нигезен табу; татар һәм рус телләрендә җөмлә кисәкләренең урнашу тәртибен күзәтү; гади җөмлә төрләрен ачыклау; модаль кисәкләрне билгеләү һәм тыныш билгеләрен дөрес кую күнекмәләрен үстерү; телдән һәм язма сөйләмдә гади җөмләләрнең өйрәнелгән төрләрен куллана белү. |
| Бәйләнешле сөйләм үстерү. | 20 | Диалогик һәм монологик сөйләм формаларына ия булу. Үз фикереңне белдерү һәм аны дәлилләү. Татар телен начаррак белүче кешеләр белән аралашканда, татар сөйләм әдәбе үзенчәлекләрен саклау.<br>Текст өстендә эшләү: аңа исем бирү, планын төзү. Тәкъдим ителгән план буенча текст төзү. |
| **9 класс-68 сәгать** | | |

| | | |
|---|---|---|
| Кушма җөмлә синтаксисы һәм сөйләм культурасы.<br>Кушма җөмлә турында гомуми төшенчә. Кушма җөмлә составындагы җөмләләрнең бәйләнеш төрләре.<br>Кушма җөмлә төрләре. Тезмә кушма җөмләләр турында үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтү (теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр,аларянындатыныш билгеләре).<br>Иярченле кушма җөмләләр турында гомуми мәгълүмат. Аналитик иярченле кушма җөмләләр. Синтетик иярченле кушма җөмләләр. Аналитик һәм синтетик иярченле кушма җөмләләрдә бәйләүче чаралар һәм тыныш билгеләре.<br>Татар һәм рус телләрендә тезмә һәм иярченле кушма җөмләләр. Аларның охшаш һәм үзенчәлекле билгеләре.<br>Иярчен җөмләләрнең мәгънә ягыннан төрләре. Җөмлә кисәкләре белән иярчен җөмлә төрләре арасындагы мәгънә бәйләнеше.<br>Иярчен ия җөмләләр. Иярчен хәбәр җөмләләр.<br>Иярчен аергыч җөмләләр. Иярчен тәмамлык җөмләләр.<br>Иярчен хәл җөмләләр: иярчен вакыт, иярчен урын, иярчен рәвеш, иярчен күләм, иярчен сәбәп, иярчен максат, иярчен шарт һәм иярчен кире җөмләләр. | 35 | Сөйләмдә туры һәм кыек сөйләмне куллана белү; җөмләнең грамматик нигезен дөрес билгеләү; гади һәм кушма җөмләләрне аеру; синтетик һәм аналитик иярченле кушма җөмләләрне телдән һәм язма сөйләмдә куллану; татар һәм рус телләрендә иярченле кушма җөмләләрнең төзелеш үзенчәлекләрен аңлау; кушма җөмләләргә синтаксик анализ ясау. |
| Текст һәм пунктуация.<br>Текст турында гомуми төшенчә. Туры һәм кыек сөйләм һәм янында тыныш билгеләре. | 5 | |
| Сөйләм культурасы. Әдәби сөйләмнең төп билгеләре: дөрес, ачык, эзлекле, сәнгатьле, аһәңле, җыйнак, матур яңгырашлы сөйләм. Татар әдәби теленең байлыгы һәм тәэсирле булуы.<br>Сөйләмдә калькаларны урынлы куллану. | 12 | Татар әдәби тенең төп нормаларына ия булу; дөрес итеп сөйләшүнең зыялы кешеләргә хас булган билге икәнлеген аңлау; ана теленә хөрмәт белән карау; төп әйтелеш кагыйдәләрен һәм сүз басымының урынын белү; орфоэпик яктан үзеңнең һәм башка кешеләр сөйләмен анализлау һәм бәяләү; сөйләмеңә төзәтүләр кертү; сөйләм культурасын<br>булдыру өчен, татар әдәби телендәге лексик байлыкның мөһимлеген аңлау; хәзерге татар әдәби теле нормалары турында |

| | | |
|---|---|---|
| | | мәгълүматны төрле чыганаклардан алу.<br>Текстларны татарчадан русчага һәм русчадан татарчага тәрҗемә итү. |
| Бәйләнешле сөйләм үстерү. | 17 | Тәкъдим ителгән план буенча төрле текстлар язу: сочинение элементлары белән изложение, сочинение-хикәяләү һ.б.<br>Аудитория алдында чыгыш ясый белү: тема сайлау, максат һәм бурычларны дөрес итеп кую, тыңлаучыларның кызыксыну даирәсен истә тоту. |

**Туган телне укыту предметыннан укучыларның белем, осталык һәм күнекмәләрен бәяләү нормалары.**

**5-9 нчы сыйныфларда язма эшләрнең саны:**

| класс | Инша | Диктант | Изложение | Контроль эш | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|
| 5 | 2(1) | 4(2) | 2(1) | 1 | 10 |
| 6 | 3(1) | 4(2) | 2(1) | 1 | 10 |
| 7 | 3(1) | 4(2) | 2(1) | 1 | 10 |
| 8 | 3(1) | 4(2) | 2(1) | 1 | 10 |
| 9 | 3(1) | 3(2) | 2(1) | 1 | 9 |

**Диктантларны бәяләүгә таләпләр.**

| № | Таләпләр | Билге |
|---|---|---|
| 1. | Орфографик һәм пунктуацион хаталары булмаган эшкә.<br>Искәрмә. Орфографик (яки пунктуацион) хаталы пөхтә башкарылган эшкә яки бер үк хата бер үк сүзләрдә кабатланса һәм бер пунктуацион хаталы эшкә | «5»ле билгесе куела. |
| 2. | 1 орфографик, 1 пунктуацион хатасы булган эшкә<br>Искәрмә. 1 орфографик, 2 пунктуацион хаталы эшкә яки, орфографик хаталары булмыйча, 3 пунктуацион хатасы булган эшкә, яки бер төрдәге 2 орфографик һәм 1 пунктуацион хаталы эшкә | «4»ле билгесе куела. |
| 3. | 2 орфографик, 1—3 пунктуацион хаталы, 2 төзәтүле эшкә<br>Искәрмә. 4 пунктуацион, 1 орфографик хаталы эшкә яки бер төрдәге 5 орфографик, 4 пунктуацион хаталы эшкә | «3»ле билгесе куела. |
| 4. | 5 орфографик, 5 пунктуацион хаталы, 4 төзәтүле эшкә | «2»ле билгесе куела. |
| 5. | 6—7 орфографик, 4—5 пунктуацион хаталы, берничә төзәтүле эшкә | «1»ле билгесе куела. |

**Сүзлек диктантларын бәяләү.**

| Сыйныфлар | Сүзләр саны |
|---|---|
| 5 | 12-14 |
| 6 | 15—18 |
| 7 | 18—20 |
| 8 | 20—22 |
| 9 | 22—25 |

Хатасыз башкарылган эшкә—«5»ле, бер-ике хаталы эшкә— «4»ле, өч яки дүрт хаталы эшкә «3»ле билгесе куела.

**Изложениеләрне бәяләү.**

| № | Текстның бирелеше | Грамоталылыгы | Билге |
|---|---|---|---|
| 1. | Текст, планга нигезләнеп (яки плансыз), эзлекле бирелгән; стиль бердәмлеге сакланган; фактик хаталар юк. | 1 орфографик яки пунктуацион (яки грамматик) хата бар. | «5»ле билгесе куела. |
| 2. | Тексттагы хикәяләү агышы бирелгән эзлеклелек белән тулысынча туры килми; стиль бердәмлегендә хилафлык сизелә; язмада 1 фактик хата җибәрелгән. | 2 орфографик, 1 пунктуацион (яки 1 грамматик) хата бар. | «4»ле билгесе куела. |
| 3. | Текст язмада эзлекле бирелмәгән, стиль бердәмлеге сакланмаган. Сүзләр бәйләнешендәге төгәлсезлекләр җөмләнең мәгънәсен бозуга китергән. Язмада 1 фактик хата җибәрелгән. | 3 орфографик, 2 пунктуацион, 1 грамматик хата бар. | «3»ле билгесе куела. |
| 4. | Тексттагы эзлеклелек язмада сакланмаган; стиль бердәмлеге юк; сүзләр һәм җөмләләр бәйләнешендә хаталар бар; фактик һәм техник хаталар күп. | Орфографик хаталарның саны — 3 тән, пунктуацион хаталарның саны — 2 дән, грамматик хаталарның саны 3 тән артык. | «2»ле билгесе куела. |
| 5. | Текстның эзлеклелеге язмада сакланмаган; сүзләр һәм җөмләләр бәйләнешендә җибәрелгән хаталар текстның эчтәлеген аңлауны кыенлаштыра, хаталар бик күп. | Төгәлсезлекләр «2»ле кую нормасыннан артып китә. | «1»ле билгесе куела. |

**Сочинение түбәндәгечә бәяләнә:**

| | Эшнең эчтәлеге һәм теле | Грамоталылыгы | Билге |
|---|---|---|---|
| 1. | Эчтәлек темага туры килә; язмада фактик ялгышлар юк; план буенча (яки плансыз) эзлекле язылган; теле бай, образлы; стиль бердәмлеге сакланган. | 1 орфографик (пунктуацион яисә грамматик) ялгыш бар. | «5»ле билгесе куела. |
| 2. | Язманың эчтәлеге темага, нигездә, туры килә, ул дөрес ачылган; 1 фактик хата җибәрелгән, хикәяләү эзлеклелегендә | 2 орфографик, 2 пунктуацион һәм 2 грамма- | «4»ле билгесе куела. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | артык әһәмияте булмаган төгәлсезлек сизелә; тулаем алганда, теле бай, образлы; стиль бердәмлеге сакланган. | тик ялгыш бар. | |
| 3. | Эчтәлекне бирүдә мөһим читләшүләр бар: ул, нигездә, дөрес, ләкин фактик төгәлсезлекләр очрый, хикәяләү эзлекле түгел; теленең ярлылыгы сизелеп тора; синонимик сүзләрне аз куллана, бертөрлерәк синтаксик төзелмәләр файдалана, образлы түгел, сүз куллануда ялгышлар җибәрә; стиль бердәмлеге сакланып җитмәгән. | 3 орфографик, 3 пунктуацион һәм 3 грамматик ялгыш бар. | «3»ле билгесе куела. |
| 4. | Тема ачылмаган; фактик төгәлсезлекләр күп; планга туры килми, эзлеклелек бозылган; теле ярлы; сүз куллану ялгышлары еш очрый; стиль бердәмлеге юк. | 7 орфографик, 7 пунктуацион һәм грамматик ялгышлар бар. | «2»ле билгесе куела. |
| 5. | Төгәлсезлекләр «2»ле билгесе кую нормасыннан артып киткән. | Ялгышлары «2»ле билгесе кую нормасыннан артык. | «1»ле билгесе куела. |

**Тестларны бәяләү**

«5» - 86-100% дөрес җавап өчен куела;

«4» - 71-85% дөрес җавап өчен куела;

«3» - 51-70% дөрес җавап өчен куела;

«2» - 0-50% дөрес җавап өчен куела;

**Укучыларның телдән сөйләм эшчәнлеген бәяләү:**

**Сорауларга җавапларны бәяләү**

Эшләрегезне бәяләгәндә, укытучы җавабыгызның тулы, төгәл, дөрес булуына, сөйләмегезнең стилистик яктан камил, орфографик һәм пунктуацион яктан грамоталы булуына игътибар итә.

Барлык сорауларга да дөрес җавап бирдегез (1 сөйләм хатасы яки 1 пунктуацион хатагыз булырга мөмкин) - "5"ле.

Сорауларга дөрес җавап бирдегез, ләкин 2 сөйләм хатасы, 3 орфографик, 2 пунктуацион хата яки 2 сорауга җавап язганда, төгәлсезлек җибәрдегез - "4"ле.

Язма эштә сорауларга җавап бирә белү күнекмәсе сизелә, 3 сөйләм хатасы, 4 орфографик, 5 пунктуацион хатагыз бар - "3"ле.

Җавапларыгызның яртысы дөрес түгел, сөйләм хаталарыгыз 3 тән артык, 5 орфографик, 6 пунктуацион хатагыз бар - "2"ле.

**5-9 нчы сыйныфлар өчен әдәбият программасын үзләштерүдән көтелгән нәтиҗәләр ( татар төркемнәре өчен):**

Урта сыйныфларда әдәбият укытуның **гомуми(метапредмет)нәтиҗәләре** түбәндәгеләр:

- укучыда әдәби әсәрне аңлап укырлык, мөстәкыйль үзләштерерлек күнекмәләр булдыру, әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләү;
- сүз сәнгатен халыкның яшәү рәвешен, рухи кыйммәтләрен саклап калган һәм беркетә килгән хәзинә буларак кабул итәргә өйрәтү;

- язу һәм сөйләм осталыгын үстерү, мәсьәләне аңлый, гипотеза куя, материалны төркемли, үз фикерен дәлилли, кирәк икән – үзгәртә-төгәлләштерә, нәтиҗәләр чыгара, материалны гомумиләштерә белергә, үз хисләреңне сүзләр ярдәмендә аңлата алырга һәм бер үк вакытта башкалар белән бергәләп эшләргә күнектерү;
- баланың үз эшчәнлеген һәм әйләнә-тирәдәге тормышны мөстәкыйль бәяли белүенә, мөстәкыйль карарлар кабул итә һәм аларны җиренә җиткереп үти алуына ирешү;
- төрле чыганаклар белән эшләргә, аларны табарга, мөстәкыйль рәвештә кулланырга, төркемләргә, чагыштырырга, анализларга һәм бәяләргә өйрәтү.

**Предмет нәтиҗәләре**:

*Танып-белү өлкәсендә*:

- аерым төр һәм жанрга караган әсәрләрне аңлап укый һәм кабул итә, эчтәлеген кабатлап (аерым очракларда текстны яттан) сөйли, кирәк чакта тексттан өзекләр китерә алуга ирешү; -укыган әдәби әсәрнең эчтәлеген, темасын, проблемасын, идеясен билгели, геройларын
һәм әдәби дөньясын бәяли алуына, аның нинди төр һәм жанрга каравын аеруына ирешү;
- укучының классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактларын белүе;
- әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгарып, укыган буенча тезислар һәм план төзү, геройларга характеристика бирү, сюжет, композиция үзенчәлекләрен, махсус сурәтләү чараларының ролен билгеләү күнекмәсе булдыру;
- укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашырга, оппонентларның фикерен исәпкә алып, үз карашларын расларга һәм дәлилләргә, әдәбият белеме төшенчәләренә мөрәҗәгать итәргә өйрәтү.

*бәяләү өлкәсендә*:

- милли әдәбияттагы рухи-әхлакый кыйммәтләрне күңелдән уздырып кабул итәргә өйрәтү;
- әдәби әсәрләргә шәхси мөнәсәбәт һәм бәя булдыру;
- өйрәнелгән әсәрләрне шәрехли белүенә ирешү;
- автор позициясен ачыклый алу һәм аңа үз мөнәсәбәтеңне булдыру күнекмәсен формалаштыру.

*эстетик яктан*:

- әдәби әсәрнең образлы табигате хакында гомуми мәгълүматый күзаллау булдыру, аның эстетик кыйммәтен тою хисе тәрбияләү;
- баланың әдәби текстны эстетик бөтенлекле, шул ук вакытта әдәби һәм тел-сурәтләү алымнарының, образлылыкның үзенчәлекләрен һәм әһәмиятен аңлап бәяли белүенә ирешү;
- рус һәм татар телендәге әдәби әсәрләрне чагыштырып бәяләргә, геройларның, әхлакый идеалларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләргә өйрәтү.

**Шәхси нәтиҗәләр**:

- укучының җаваплылык хисен активлаштыру;
- укуга һәм хезмәткә уңай мөнәсәбәт булдыру;
- баланың үзаңын үстерү, милләтне, ватанны яратырга өйрәтү, горурлык һәм гражданлык хисләре тәрбияләү;
- әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен төшендерү;
- төрле чыганаклардан (сүзлекләр, энциклопедияләр, интернет-ресурслар һ.б.) танып-белү һәм коммуникатив ихтыяҗларны канәгатьләндерерлек мәгълүматлар табарга күнектерү.

**Предметара нәтиҗәләр**:

- укучыларда әдәбиятны сәнгатьнең башка төрләре ярдәмендә мөстәкыйль үзләштерерлек күнекмәләр булдыру һәм әдәбият–сәнгать белән даими кызыксыну формалаштыру;

- татар теленә бәйләнештә, туган телнең матурлыгына һәм байлыгына хөрмәт тәрбияләү;
- мәдәниятара бәйләнешләрне саклау, укучының башка милләтләр мәдәнияте һәм әдәбиятыннан мәгълүматлы, башка халыкларның сүз сәнгатенә хөрмәтле мөнәсәбәттә, толерант булуына ирешү.

## V- IX сыйныфларда әдәбият укыту предметының эчтәлеге

**Әдәбият тарихы**

***Әдәбият тарихын*** өйрәнү халык авыз иҗатыннан башлана.

**Халык авыз иҗаты**

Халыкның милли рухи культура хәзинәсе буларак халык авыз иҗаты. Фольклор әсәрләрендә гомумкешелек кыйммәтләренең зур урын тотуы. Халык иҗатының язма әдәбият үсешенә, әдәби телгә зур йогынты ясавы. Фольклорның төп жанрлары. Әкиятләр. Мәкаль һәм әйтемнәр. Табышмаклар. Мәзәкләр. Җырлар. Бәетләр. Риваятьләр һәм легендалар.

**Борынгы, урта гасырлар татар әдәбияты**

Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятының мифологиягә һәм халык авыз иҗатына нигезләнүе. Ислам дине идеологиясе белән сугарылуы. Шәрык әдәбиятлары йогынтысы. Күчмә сюжетлар. Әсәрләрнең тематик төрлелеге һәм проблематикасы: гадел хөкемдар, кеше һәм Алла, шәхес һәм җәмгыять мөнәсәбәте, илаһи мәхәббәт һәм җир мәхәббәте, гаделлек, миһербанлылык, сабырлык. Әдәбиятта дини-әхлакый, суфыйчыл һәм дөньяви карашларның үрелеп баруы. Жанрлар төрлелеге.

**XIX йөз әдәбияты**

Бер яктан, урта гасыр әдәбияты традицияләренә нигезләнүе, икенче яктан, җәмгыятьтәге үзгәрешләргә бәйле яңа сыйфатлар белән баюы: реализм юлына чыгу, яңа төрләр һәм жанрлар барлыкка килү, сурәтләүнең яңа алым-чараларына мөрәҗәгать итү. Мәгърифәтчелек чоры әдәбиятының үзенчәлекләре. Һәртөр искелеккә каршы көрәшеп, идеал кеше образы тудырылу. Әдәбиятның чынбарлык проблемаларына мөрәҗәгать итүе. Яңа заман сүз сәнгатенә нигез салыну.

**XX гасыр татар әдәбияты**

Иҗтимагый-тарихи вакыйгаларның әдәбиятка тәэсире. Татар сүз сәнгатенең Шәрык һәм рус-Европа әдәби-фәлсәфи, мәдәни казанышларын үзләштерүе. Кеше һәм җәмгыять проблемасы.Чынбарлыкны реалистик һәм романтик чагылдыру үзенчәлекләре. Әхлакый һәм фәлсәфи эзләнүләр. Яңарыш чоры әдәбиятының әһәмияте.

Совет чоры татар әдәбиятының каршылыклы үсеше. Төп тема-проблемалар. Әдип һәм җәмгыять мөнәсәбәте. Бөек Ватан сугышы һәм татар әдәбияты. Илленче еллар ахырыннан башлап әдәбиятта сыйфат үзгәрешләре башлану. Сүз сәнгатендә милләт проблемасының алгы планга чыгуы. Әдипләрнең заман проблемаларына актив мөрәҗәгать итүе. Җәмгыятьтәге үзгәрешләрнең әдәбиятта чагылышы.

**Төп әдәби-тарихи мәгълүматлар**

Матур әдәбиятның тормышны танып белүнең бер формасы булуы һәм анда кеше рухи дөньясының байлыгы, күптөрлелеге чагылуы. Әдәбият һәм сәнгатьнең башка төрләре. Сүз сәнгатенең төп асылы (әхлаклылык, миһербанлылык тәрбияләү, яшәүнең төп принципларын, дөньяга дөрес караш, эстетик зәвык формалаштыру һәм, гомумән, гомумкешелек кыйммәтләре белән таныштыру).

Матур әдәбиятның иҗтимагый һәм мәдәни тормыштагы урыны. Татар әдәбиятының милли үзенчәлеге, гуманистик эчтәлеге, традицияләр дәвамчанлыгы һәм яңачалык. Татар әдәбияты мөрәҗәгать иткән тема-мотивлар, гомумкешелек кыйммәтләре.

**Төп әдәби-теоретик төшенчәләр**

Сүз сәнгате буларак әдәбият. Язма әдәбият һәм фольклор. Халык авыз иҗаты жанрлары. Әдәби төрләр һәм жанрлар. Әдәби образ.

Әдәби әсәрнең формасы һәм эчтәлеге: тема, проблема, идея, сюжет, композиция; сюжет элементлары; конфликт, автор образы, хикәяләүче образы; лирик герой.

Әдәби әсәрнең теле. Әдәби сурәтләү чаралары: чагыштыру, эпитет, метафора, гипербола, метонимия, символ, аллегория, җанландыру. Пейзаж. Портрет. Юмор һәм сатира.

Шигырь төзелеше: ритм, рифма, строфа.

## Укучыларның белеменә, эш осталыгына һәм күнекмәләренә таләпләр

Әдәбият предметын үзләштерү нәтиҗәсендә укучы:
- сүз сәнгатенең образлы табигатен;
- милли әдәбиятның иң билгеле язучыларыннан Г.Тукайның, Г.Камалның, Г.Ибраһимовның, Ф.Әмирханның, Г.Исхакыйның, М.Җәлилнең, Ә.Еникинең тормыш юлы һәм иҗатының төп фактларын;
- өйрәнелгән әсәрләрнең эчтәлеген;
- сүз сәнгатенең образлы асылын;
- төп әдәби-теоретик төшенчәләрне **белергә**;
- әдәби әсәр эчтәлеген кабатлап, аерым өлешләрен яттан сөйләү;
- әдәби әсәрне әдәбият теориясеннән мәгълүматлар файдаланып анализлау;
- әдәби әсәрнең аерым якларын элементларын җентекләп тикшерү һәм нәтиҗәләр чыгару;
- әдәби әсәрнең төр һәм жанрын билгеләү;
- әдәби әсәрләрне, аларның геройларын чагыштыру;
- геройларга характеристика бирү, автор позициясен ачыклау;
- сәнгатьле уку;
-әдәби әсәрләр хакында төрле характердагы иҗади эшләр башкару
күнекмәләрен үзләштергән булырга тиеш.

**<u>Әдәбиятны укыту предметының уку эшчәнлеге төрләре күрсәтелгән тематик планы</u>**

| Программаның төп темалары | Сәгатьләр саны | Уку эшчәнлегенең төп төрләре |
|---|---|---|
| **5 класс- 35 сәгать** | | |
| Халык авыз иҗаты һәм аның җанрлары | 8 | Төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлап һәм иҗади уку.<br>Әсәрләрне анализлау һәм шәрехләү.<br>План төзү һәм әсәрләр турында бәяләмә (отзыв) язу.<br>Әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру;<br>Әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку, укыганга үзенең мөнәсәбәтен белдерү. |
| Урта гасыр әдәбияты үрнәкләре | 4 | |
| XXгасыр башы әдәбияты | 4 | |
| Бөек Ватан сугышы чоры һәм сугыштан соңгы әдәбият | 9 | |
| Минем Ватаным | 5 | |
| Тәрҗемә | 2 | |
| Язучылар иҗатында юмор | 3 | |
| **6 класс-35 сәгать** | | |
| Халык авыз иҗаты. Җырлар. | 3 | Әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку, укыганга үзенең мөнәсәбәтен белдерү.<br>Төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлап һәм иҗади уку.<br>Әсәрләрне анализлау һәм шәрехләү.<br>План төзү һәм әсәрләр турында бәяләмә (отзыв) язу.<br>Әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру.<br>Укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашу, фикерләрне дәлилле белү. |
| 18,19 гасыр әдәбияты үрнәкләре | 3 | |
| XXгасыр башы әдәбияты | 8 | |
| Бөек Ватан сугышы чоры һәм сугыштан соңгы әдәбият | 7 | |
| Туган як матурлыгы | 6 | |
| Тәрҗемә | 2 | |
| Туган телем. Язучылар иҗатында юмор | 6 | |
| **7 класс- 35 сәгать** | | |
| Халык авыз иҗаты. | 5 | Төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлап һәм иҗади уку.<br>Әдәби әсәрдәге эпизодларны |
| 18,19 гасыр әдәбияты үрнәкләре | 4 | |
| XXгасыр башы әдәбияты | 9 | |

| | | |
|---|---|---|
| Бөек Ватан сугышы чоры һәм сугыштан соңгы әдәбият | 13 | һәм геройларны чагыштыру.<br>Укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашу, фикерләрне дәлилли белү.<br>Өйрәнгән әдәби-теоретик төшенчәләрне истә калдыру.<br>Әдәби текстны кабул итү һәм анализлау;<br>Әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгару, укыган буенча тезислар һәм план төзү. |
| Фантастика | 2 | |
| Тәрҗемә | 2 | |
| **8 класс- 35 сәгать** | | |
| Халык авыз иҗаты. | 3 | Әдәби текстны кабул итү һәм анализлау.<br>Әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру.<br>Укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашу, фикерләрне дәлилли белү.<br>Өйрәнгән әдәби-теоретик төшенчәләрне истә калдыру.<br>Әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгару, укыган буенча тезислар төзү.<br>Тема, проблема, жанр уртаклыклары нигезендә татар һәм рус әдәбиятындагы әсәрләрне чагыштырып бәяләү;рустелендәгеәдәби текстларны татарчага һәм киресенчә тәрҗемә итү. |
| 18,19 гасыр әдәбияты үрнәкләре | 3 | |
| XXгасыр башы әдәбияты | 5 | |
| XXгасырның II яртысында әдәбият | 9 | |
| Драма жанры | 4 | |
| Шигърият | 3 | |
| Хикәя | 7 | |
| Тәрҗемә | 1 | |
| **9 класс-34 сәгать** | | |
| Халык авыз иҗатыннан язма мираска | 5 | Әдәби текстны кабул итү һәм анализлау.<br>Укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашу, фикерләрне дәлилли белү.<br>Өйрәнгән әдәби-теоретик төшенчәләрне истә калдыру.<br>Әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгару, укыган буенча тезислар төзү.<br>Тема, проблема, жанр уртаклыклары нигезендә татар һәм рус әдәбиятындагы әсәрләрне чагыштырып бәяләү.<br>Рус телендәге әдәби текстларны татарчага һәм киресенчә тәрҗемә итү. |
| 19 гасыр әдәбияты | 6 | |
| Драма жанры үсеше | 6 | |
| XXгасыр башы әдәбияты | 4 | |
| XXгасырның II яртысында әдәбият | 9 | |
| Публицистика | 2 | |
| Тәрҗемә | 2 | |

**Укучыларның телдән сөйләм эшчәнлеген бәяләү:**
**Сөйләм күнекмәсен бәяләү**

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча логик яктан эзлекле һәм эчтәлеге ягыннан тулы монологик сөйләм төзи аласыз, бирелгән әсәр яки өйрәнелгән тема буенча әңгәмә кора беләсез - "5"ле.

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча логик яктан эзлекле, әмма эчтәлеге ачылып бетмәгән монологик һәм диалогик сөйләм өчен "4"ле аласыз.

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән тема буенча логик яктан эзлекле итеп сөйли белмисез, эчтәлекне ачып бетерә алмыйсыз, әңгәмәдә өстәмә сораулар бирелгәндә генә катнашасыз - "3"ле.

Өйрәнелгән яки тәкъдим ителгән темага монолог та, диалог та төзи алмыйсыз - "2"ле.

**Анализ күнекмәләре һәм теоретик белемнәрне бәяләү**

Әсәрне анализлау яки чорга характеристика бирү барышында әдәби-теоретик төшенчәләрне аңлап, урынлы кулланасыз, анализыгыз нигезле, җавабыгыз теоретик яктан югары оештырылган - "5"ле.

Әсәрне анализлау яки чорга характеристика бирү барышында әдәби-теоретик төшенчәләрне куллану барышында аерым төгәлсезлекләр җибәрәсез, анализ эчтәлек сөйләүгә "борыла" - "4"ле.

Әсәрне анализлау яки характеристика бирү барышында әдәби-теоретик төшенчәләр кулланасыз, әмма алар күренешкә туры килми, хаталар ясыйсыз; анализ әсәр эчтәлеген кабатлап сөйләүдән генә гыйбарәт - "3"ле.

Әсәрне анализлау яки характеристика бирү барышында әдәби-теоретик төшенчәләрдән мәгълүматсыз булуыгыз күренә, аларны җавабыгызда кулланмыйсыз, анализ бөтенләй юк - "2"ле.

**Сорауларга җавапларны бәяләү**

Эшләрегезне бәяләгәндә, укытучы җавабыгызның тулы, төгәл, дөрес булуына, сөйләмегезнең стилистик яктан камил, орфографик һәм пунктуацион яктан грамоталы булуына игътибар итә.

Барлык сорауларга да дөрес җавап бирдегез (1 сөйләм хатасы яки 1 пунктуацион хатагыз булырга мөмкин) - "5"ле.

Сорауларга дөрес җавап бирдегез, ләкин 2 сөйләм хатасы, 3 орфографик, 2 пунктуацион хата яки 2 сорауга җавап язганда, төгәлсезлек җибәрдегез - "4"ле.

Язма эштә сорауларга җавап бирә белү күнекмәсе сизелә, 3 сөйләм хатасы, 4 орфографик, 5 пунктуацион хатагыз бар - "3"ле.

Җавапларыгызның яртысы дөрес түгел, сөйләм хаталарыгыз 3 тән артык, 5 орфографик, 6 пунктуацион хатагыз бар - "2"ле.

## РУС ТЕЛЕНДӘ УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕНДӘ ТУГАН ТЕЛ ПРЕДМЕТЫН УКЫТУ ПРОГРАММАСЫ

## (рус телендә сөйләшүче 5-9 нчы сыйныф укучылары өчен)

### Төп гомуми белем бирү баскычында “Туган тел” предметын укытуга укытуның планлаштырылган нәтиҗәләре

Укытуның **шәхескә кагылышлы нәтиҗәләре:**

– укучыларда күпмилләтле җирлектә яшәүче халыкларга карата ихтирамлык, гражданлык бердәйлеге хисләре формалаштыру;

– *туган җир, Ватан* төшенчәләре,үз культураң аша дөнья культурасына каратаихтирам тәрбияләү, аны өйрәнү теләге формалаштыру;

– үзлегеңнең белемеңне арттыру һәм үз-үзеңне тәрбияләү нигезендә, үз эшчәнлегеңне оештыра алу осталыгын формалаштыру;

– әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;

– әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирә белү.

Укытуның **метапредмет нәтиҗәләре**Төп белем бирү баскычында татар теле, танып белү чарасы буларак, укучыларның

фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен формалаштыруга хезмәт итә.

***Танып белү нәтиҗәләре*:**

– фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;

– иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм төзи белү;

– объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгели белү;

– төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;

– тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллана белү.

***Регулятив нәтиҗәләр*:**

– уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү, ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләр формалашу;

–эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;

–билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү;

–укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү.

***Коммуникатив* нәтиҗәләр:**

–әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;

–әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзи белү;

–аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре формалашу;

–парларда һәм күмәк эшли белү.

Укытуның **предмет нәтиҗәләре**

Укучының төп гомуми белем бирү мәктәбен тәмамлаганда, **сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча түбәндәге предмет нәтиҗәләренә ия булуы** планлаштырыла:

***диалогик сөйләм:***

– стандарт ситуацияләрдә сөйләмне башлый,дәвам итә,төгәлли белү;
– парлап яки күмәк сөйләшү барышында,үз фикереңне аңлата,раслый,дәлиллибелү; ситуация аңлашылмаганда, сорау биреп ачыклый белү;
– риза булмау,үтенечне кире кага белү;
– бергә эшләргә тәкъдим итә белү.

***монологик сөйләм:***

– укыганның,ишеткәннең төп эчтәлеген җиткерә белү,үз мөнәсәбәтеңне белдерү;
– сораулар ярдәмендә,план буенча яисә мөстәкыйль рәвештә өйрәнгән текстны үзсүзләрең белән сөйли белү;
– текстны дәвам итеп,үзгәртеп сөйли белү;
– программада тәкъдим ителгән темалар буенча тиешле эзлеклелектә сөйли белү;
– төрле вакыйгалар,яңалыклар турында хәбәр итә белү;

– персонажларны тасвирлый белү.

***тыңлап аңлау:***

– сүзләрне,җөмләләрне тулысынча яки өлешчә тыңлап аңлау;

– сыйныфташларыңның сөйләмен тыңлап аңлый һәм аларга үз фикереңне аңлата,алар белән әңгәмә кора, әңгәмәдә катнаша белү;

– тәкъдим ителгән текстны тыңлап, эчтәлеге буенча сорау җөмләләр төзи, сорауларга җавап бирә белү;

– зур булмаган аутентив яки адаптацияләнгән әдәби әсәрләрдән өзекләрне,мәгълүмати характердагы текстларны, вакытлы матбугат язмаларын аңлап, эчтәлеге буенча фикереңне әйтә белү.

***уку:***

– татар теленең әйтелеш нормаларын саклап,сәнгатьле һәм аңлап укый белү;

– текстның эчтәлегенә нигезләнеп,контекст буенча яңа сүзләрнең мәгънәсен аңлыйбелү;

– күрмә-символик мәгълүматлы,иллюстрацияле,таблицалы текстлар белән эшләүкүнекмәләренә ия булу;

– текст укыганда,кирәкле мәгълүматны аерып алу,системага салу,чагыштыру,анализлау, гомумиләштерү, интерпретацияләү һәм үзгәртү кебек эшчәнлекләрне үзләштерү;

– текстның эчтәлегенә нигезләнеп,контекст буенча яңа сүзләрнең мәгънәсен аңлыйбелү.

***язу:***

– өйрәнелгән темалар буенча актив кулланылышта булган сүзләрне дөрес яза белү;

– конкрет бер тема буенча хикәя төзеп яза белү;

– прагматик текстлар(рецептлар,белдерүләр,афиша һ.б.),эпистоляр жанртекстларын (шәхси һәм рәсми хатлар, котлаулар һ.б.) төзеп яза белү;

– үзеңне борчыган проблемага карата фикерләреңне язмача җиткерә белү;

– тәкъдим ителгән текстның эчтәлегенә нигезләнеп,аны үзгәртеп яки дәвам итеп язабелү;

– терәк сүзләр ярдәмендә кечкенә хикәя төзеп язу.

**5 нче сыйныф**

| Предмет буенча билгеләнгән тематик эчтәлек | Сәгать саны | Тема буенча предмет нәтиҗәсе, коммуникатив максат |
|---|---|---|
